| Татар әдәбиятында шагыйрәләр иҗаты: Л.Шагыйрьҗан, | Укыган әдәби әсәрнең эчтәлеген, темасын, проб-лемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби | | Төрле чыганаклар белән эшләргә, аларны табарга, мөстәкыйль рәвештә кулланырга, төркемләргә, | Төрле чыганаклардан (сүзлекләр, энциклопедияләр, интернет-ресурслар |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Э.Мөэминова, Н.Сафина, Р.Вәлиева, Б.Рәхимова, Э.Шәрифуллина, А.Минһаҗева. Шагыйрәләр иҗатын өйрәнеп, проектлар яклау дәресе. | дөньясын бәяли алуына, аның нинди төр һәм жанрга каравын аеруына ирешү; укучының классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын белүе; | | чагыштырырга, анализларга һәм бәяләргә өйрәтү. | һ.б.) танып-белү һәм коммуникатив ихтыяҗларны канәгатьләндерерлек мәгълүматлар табарга күнектерү. |

## 9 нчы сыйныфта программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр

### Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

**Укучыда формалашачак:**

- әдәбиятның кеше тормышындагы ролен билгели алу;
- үз халкыңның тарихы,мәдәнияте, әдәбияты белән горурлану хисләре тәрбияләү;
- милләткә мәхәббәт хисенең тирәнлеген,милләткә хезмәт итүнең бөеклегенә төшенү;
- әсәр геройлары үрнәгендә үзеңдә уңай сыйфатлар булдыру;
- янәшәдәге кешеләргә игътибарлылык, дусларга карата хөрмәт хисе булу,һөнәр турында җитди караш булдыру;
- әсәрдә гореф- гадәт һәм йолаларның бирелеше һәм аларга карата ихтирам хисләре булдыру;
- әсәргә салынган идеянең кыйммәтен кабул итү аша үз - үзеңне тәрбияләү;
- әдәби әсәрләр нигезендә әхлак тәрбиясе һәм патриотик тәрбия алу;
- әдәби әсәрләр үрнәгендә өлкән буынга ихтирамлы булу,гомумкешелек сыйфатларына ия булу;

***Укучы формалашырга мөмкинлек алачак:***

- *илебез азатлыгы өчен көрәшкән сугышчыларга хөрмәт хисенә төшенү, Ватаныбыз тарихына сакчыл караш тәрбияләү;*
- *рухи байлыкның зур бәхет булуын тәрбияләү.*

### Метапредмет нәтиҗәләр

**Танып белү гамәлләре:**
**Укучы өйрәнә**

-гомум уку гамәлләре (танып белү мәсҗәләсен аңлау,төрле ңанрдагы текстлардан кирәкле мәглүматны аерып чыгару,өйрәнелә торган материал эчендә төп фикерне билгеләү,белемне структуралаштыру,нәтиҗәләр,гомумиләштерүләр ясау);
- логик уку гамәләре (билгеләрне аерып чыгару максаты белән обүектларны анализлау,обүектларны чагыштыру,классификаөияләү критерийларын эшләү,сәбәп –нәтиҗә бәйләнешләрен билгеләү).

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала***

- *проблема кую һәм аны хәл итү (проблеманы тәкүбир итү,иҗади һәм эзләнү характерындагы проблемаларны хәл итү чараларын мөстәкыйлҗ эшләү).*

**Коммуникатив гамәлләр:**
**Укучы өйрәнә:**

-хезмәттәшлек итү;
- тел нормаларына туры китереп,монолог төзү һәм диалогта катнашу осталыгына ия булу;
- үз фикерләрен тәгъбир итү;
- текст эчтәлеген өлешләргә бүлеп сөйләү;
- фикерләрне дәлилләп җиткерү;
- сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү.

***Укучы өйрәнергә мөмкинлек ала:***
- *фикерләрне эзлекле рәвештә,мисаллар белән дәлилләп, телдән һәм язмача формалаштыру.*

**Регулятив гамәлләр:**
**Укучы өйрәнә:**

- уку мәсәләсен кую;
- фаразлау;
- үз эшчәнлекне планлаштыру һәм оештыру;
- анализ барышын төзү;
- үзенең һәм башкаларның эшчәнлекләрен контролждә тотып бәяди алу;
- үзанализ һәм үзбәя ясау.

| **Бүлек исеме** | **Предмет нәтиҗәләре** | |
|---|---|---|
| | **Укучы өйрәнәчәк** | ***Укучы өйрәнергә мөмкинлек алачак*** |
| Сәнгать төре буларак әдәбият | - нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белү, үз хисләреңне сүзләр ярдәмендә аңлата алу һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләү | -*милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңел аша уздырып кабул итәргә өйрәнү;*<br>- *өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү;* |

| | | |
|---|---|---|
| | күнекмәләренә ия булу;<br>- узган сыйныфларда өйрәнгән әсәрләр мисалында XX гасыр башы татар әдә-биятының сүз сәнгате буларак үзенчәлекләрен билгели алу. | *геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу;*<br>*- төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү.* |
| Борынгы, урта гасырлар гомумтөрки әдәбият | - төрки халыклар, татарларның борынгы бабалары турында тарихи-әдәби мәгълүматларны өйрәнү;<br>- борынгы, урта гасырлар төрки-татар әдәбиятының үсеш этапларын белү;<br>- татар әдәбиятының бер өлеше буларак гомумтөрки әдәбияты һәм фольклорын, Орхон-Енисей истәлекләрен, аларда борынгы төрки халыкларының тарихы, ышануы, әдәби фикерләү үзенчәлекләренең чагылышын өйрәнү;<br>- М.Кашгариның “Диване лөгат эт-төрк” әсәре.Й.Баласагунлы “Котадгу белек”–төрки халыкларының беренче классик поэмасын өйрәнү;<br>- XII-XIII гасырларда Болгар-татар әдәбияты, К.Гали “Кыйссаи Йосыф”-кеше хисләренең бөеклеге, матурлык, зирәклек гимны булуын ачыклау;<br>- татар әдәбиятында Яңарыш чоры буларак Алтын Урда әдәбияты . Котб, Сәиф Сараи, Хәрәзми иҗатын белү. | *- төрле чыганаклар белән эшли белү: аларны таба, мөстәкыйль рәвештә куллана, төркемли, чагыштыра, анализлый һәм бәяли алу;*<br>*- сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм беркетә килгән хәзинә буларак кабул итү;*<br>*- төрки-татар әдәбиятында суфичылык юнәлеше;*<br>*- Казан ханлыгы чоры әдәбиятына гомуми бәяләмә. Казан ханлыгының рус дәүләтенә кушылуы. М.Колыйның фәлсәфи-дидактик хикмәтләрендә татар җәмгыятенең кризис хәленең чагылуы;*<br>*- дини-суфичыл фикерләрне билгели алу, автор позициясен ачыклау һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсенә ия булу;*<br>*әдәби текстны тел-сурәтләү алымнарының, образлылыкның үзенчәлекләрен һәм әһәмиятен аңлап бәяли белү* |
| XIX гасыр татар әдәбияты. | - Г.Курсави, И.Хәлфин, К Насыйри, Ш.Мәрҗәни, Х.Фәизханов, И.Гаспринскийның мәгърифәтчелек | *- өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү;*<br>*- геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу;* |

| | | |
|---|---|---|
| | эшчәнлеге белән танышу;<br><br>- Г.Кандалый, Акмулла иҗатында реалистик поэзия формалашу этапларын күзәтү. Татар реалистик прозасы формалашуны күзәтү. | - *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү;*<br>- *милли әдәбияттагы рухи-әхлакый кыйммәтләрне күңел аша уздырып кабул итәргә өйрәнү.* |
| Әдәбиятта яңа төрләр һәм жанрлар барлыкка килү | - әдәбиятта яңа төрләр һәм жанрлар барлыкка килүне белү;<br><br>- З.Бигиевнең «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романын уку һәм анализлау. Татар халкының үсеш яңарыш кичерүе өчен, мондый темаларның актуаль булуы, татар хатын-кызы язмышы, рус мәдәниятенә йөз тотуны күзәтү, тиешле нәтиҗә ясый белү. | - *нәтиҗәләр чыгара, материалны гомумиләштерә белү, үз хисләреңне сүзләр ярдәмен-дә аңлата алу һәм бер үк вакытта башкалар белән бергәләп эшләү күнекмәләренә ия булу;әхлак нормаларын, җәмгыятьт тә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү.* |
| 20 гасыр башы татар әдәбияты. | - сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүен күзәтү.<br>- Ф.Әмирханның. «Хәят» повестен уку һәм анализлау.<br>- Модернизм, модернизм алымнарын өйрәнү. Материалны төркемли, үз фикереңне дәлилли, нәтиҗәләр чыгара, өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү;<br>- геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу. Г.Камал “Банкрот” әсәрен өйрәнү. | - *әйләнә-тирәдәге тормыш¬ны мөстәкыйль бәяли белү;*<br><br>- *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү;*<br><br>- *әдәбиятны теләп, яратып укуга омтылу; әдәби текстны эстетик яктан бәяли белү;*<br><br>- *сүз сәнгатен халыкның яшәү рәвешен, рухи кыйммәтләрен саклап калган һәм бер-кетә килгән хәзинә буларак кабул итү, әдәби алымнарны табып, шулар нигезендә фәлсәфи фикерне ачыклау күнекмәсенә ия булу;*<br><br>- *язу һәм сөйләм* |
| XX гасырның беренче яртысында татар | - 1917 елдан соңгы татар әдәбияты үсешендә очраган кыенлыкларны күзәтү; | - *өйрәнелгән әсәрләрне мөстәкыйль шәрехли белүгә ирешү;* |

| | | |
|---|---|---|
| әдәбияты | - эпик төр буларак роман жанрының активлашу этапларын белү;<br>- М.Галәү “Мөһаҗирләр” романын өйрәнү.Романның эчтәлеген, темасын, проблемасын, идеясен билгели, геройларын һәм әдәби дөньясын бәяли алу, автор позициясен ачыклый алу һәм аңа үз мөнәсәбәтеңне булдыру күнекмәсенә ия булу;<br>- әдәби текстны эстетик бөтенлекле, шул ук вакытта тел-сурәтләү алымнарының, әһәмиятен аңлап бәяли белү. | - *әйләнә-тирәдәге тормышны мөстәкыйль бәяли белү;*<br>- *әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагый-дәләрен үзләштерү;*<br>*үз фикереңне дәлилли, кирәксә- үзгәртә-төгәлли, нәтиҗәләр чыгара белү* |
| Бөек Ватан сугышының әдәбиятка йогынтысы | - сугыш еллары поэзиясенең төп тема-мотивлары, образлары, поэтикасын белү.<br>- Г.Кутуйның “Сагыну” нәсерен өйрәнү;<br>- Муса Җәлилнең “Тик булса иде ирек”, “Җырларым” шигырьләрен өйрәнү.М.Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗатын белү;<br>- Ә.Еникинең “Кем җырлады” хикәясен өйрәнү. Шигырьләрне тиешле ин¬тонация, пафос белән, логик басымнарны шигырьдәге мәгъ¬нәләргә туры килерлек итеп куеп, тиешле урында паузалар ясап укуга ирешү;<br>- образларны күрсәтеп, алар арасындагы бәйләнешләрне аңлата алу;<br>- фикер һәм хис тәңгәллеген, су¬рәтләү чараларын анализлый белү. Әсәрнең язылу вакытына игътибар итеп, сугыш чоры тудырган авырлык, | - *Бөек Ватан сугышының максатларын, характерын һәм анда катнашкан халыкларның сугышка мөнәсәбәтен истә тотып, Бөек Җиңүнең кыйммәтен бәяли алу;*<br>- *Бөек Ватан сугышы чорында иҗат ителгән әдәбиятның үзенчәлекләрен күрсәтә белү.* |

| | | |
|---|---|---|
| | фаҗигаләр һәм аларның сәбәпләре турында аңлата белү. | |
| XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты | - XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуын күзәтү;<br>- А.Гыйләҗевның «Җомга көн, кич белән» повестен өйрәнү. Татар әдәбиятының милли традицияләргә кайтуы, тарихи роман җанры барлыкка килүен күзәтү. Н. Фәттахның "Ител суы ака торур» романын уку.Әсәрнең исеменә салынган күчерелмә мәгънәне вакыйгалар белән бәйли, табигать белән тәңгәл килгән матурлыкны – әсәрнең поэтикасын, сәнгатьлелек чараларын анализлый белү. | - *Өйрәнелгән әсәрләрне шәрехли белүгә ирешү;*<br>- *геройларның, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү күнекмәсенә ия булу;*<br>- *төрле чыганаклардан мәгълүматлар таба белү;*<br>- *әдәбиятны теләп, яратып укуга омтылу.* |
| XX-XXI гасырлар чигендә татар әдәбияты. Совет чоры җәмгыятенең актуаль проблемалары. Халык традицияләрен саклау һәм яңарыш проблемалары | - XX-XXI гасырлар чигендә татар әдәбиятының үзгәрүе: совет һәм аннан соңгы чорга тәнкыйди бәя бирергә өйрәнү;<br>- Зөлфәтнең «Тамыр көлләре», «Тойгыларда алтын яфрак шавы» шигырьләрен өйрәнү. Кеше һәм җәмгыять каршылыгы күзлегеннән ил тормышының аерым этапларын сурәтләүче әдәби әсәрләрнең барлыкка килүен күзәтү;<br>- Ф.Садриевның «Таң җиле» романын уку һәм анализлый алу;<br>- Т.Миңнуллин "Кулъяулык" әсәрен өйрәнү | - |

## Уку предметының эчтәлеге

## 5 нче сыйныф

| № | Бүлекләр исеме | Эчтәлек | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1. | **Халык авыз иҗаты**<br><br>**Татар халык әкиятләре** | Татар халкының милли, рухи мәдәниятенең байлыгы буларак халык авыз иҗаты. Фольклор әсәрләренең мөһим өлеше буларак гомумкешелек кыйммәтләре. Халык авыз иҗаты әсәрләрендә образлар системасы. Фольклорда дөнья картинасы: геройлык, игелек һәмявызлык, тормыш һәм кеше, кеше һәм табигать турында күзаллау. Фольклор әсәрләренең шигъри үзенчәлекләре: чагыштыру, гәүдәләнеш, метафоралылык , аллегориялелек.<br><br>Татар халык әкиятләре (1-4 классларда өйрәнелгәнне кабатлау) Әкиятләр, төрләре (тылсымлы әкият «Ак бүре"»). Көнкүреш әкиятләре. Хайваннар турында әкиятләр. Фольклор әсәрләренең поэтикасы(аерым детальләрдә фантастик яки мифологик сюжет, тормышчанлык, кабатлау, гипербола, литота,каршы кую( антоним) кебек сәнгать алымнарын куллану) | 6 |
| 2. | **Халык авыз иҗатында җыр жанры.** | Җырлар: татар халык җырларына хас үзенчәлекләр. Көй һәм сүзләр тәңгәллеге.“Моң” төшенчәсе. Җырларны төркемләү. “Иске кара урман”, ”Гөлҗамал”,”Туганил”,”Яшә, Республикам!”,”Ай былбылым”; кыска җырлар - дүртюллыклар; тарихи җырлар:“Болгар иленең кызлары”,”Пугач явы”. | 2 |
| 3. | **Халык авыз иҗа-тында кыска жанр-лар: мәкальләр һәм әйтемнәр, табыш-маклар, мәзәкләр.** | Кыска фольклор жанрлары. Мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар һәм мәзәкләр. Халык психол-огиясе, фольклор әсәрләрендә идеаллар һәм кузаллаулар | 4 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4. | **Бәетләр. “Сак-сок” бәете. БСҮ. “Сак-Сок” бәетендә тас-виланган халык акылы.** | Үзләре укыган, ишеткән бәетләрне сөйләү, фикер алышу. Бәетне уку һәм анализлау, текстка якын килеп эчтәлеген сөйләү | 2 |
| 5. | Риваятьләр, легендалар. “Янмый торган кыз”, ”Иске Казан каласының корылуы”,”Шәһәр нигә Казан дип аталган”,”Әллүки”,”Зөһрә кыз”,”Кеше гомере ничек корылган” | Риваять һәм легендаларны уку, анализлау. Башка халык авыз иҗаты әсәрләре белән чагыштыру, сурәтләү чараларын табу | 2 |
| 6. | Практик дәрес. Халык авыз иҗатында образлар | “Ак бүре”, “Үги кыз” әкиятләрендәге образларны тикшерү, әңгәмәдә катнашу. “Образ (сурәт)”, “поэтика” төшенчәләрен өйрәнү | 1 |
| 7. | Әдәби әкиятләр. Г.Тукай “Шүрәле” | Әдәби әкиятләргә мисаллар китерү. Эчтәлекләрен искә төшереп сөйләү. Әкият-уку һәм анализлау. Поэмада вакыйгаларны, төп геройларны күрсәтү | 1 |
| 8 | Ж.Тәрҗемановның “Тукран малае Шуктуган” әкияте | Текстны уку, сорауларга җавап эзләү, әкиятнең эчтәлеген аңлау, төп фикерне билгеләү | 2 |
| 9 | Әхмәт Фәйзинең “Аучы Мәргән белән Болан кыз” әкияте | Әкиятне уку, төп фикерне аеру, әкият геройларына бәя бирү, сөйләү, әңгәмәдә катнашу | 2 |
| 10 | Рабит Батулланың “Курай уйный бер малай” әкияте | Әсәр буенча әңгәмә кору, үз мөнәсәбәтләрен белдереп, әкиятнең эчтәлеген сөйләү | 1 |
| 11 | Фәнис Яруллинның “Зәңгәр күлдә ай коена”, “Кояштагы тап” әкиятләре | Укытучы сөйләвен тыңлау, язучы биографиясе буенча хронологик таблица төзү. Әкиятләрне уку, әкият буенча сорауларга җавап бирү, биремнәрне үтәү, геройга бәя бирү | 2 |
| 12 | Хикәя. Фатих Әмирханның “Ай өстендә Зөһрә кыз”, “Нәҗип” хикәяләре | Хикәяләрне уку, анализлау, хис-кичерешләргә, геройларга бәя бирү, сурәтләү чараларын табу, хикәянең үзенчәлекләрен билгеләп, төшенчә итеп чыгару | 2 |
| 13 | Мәсәл. Мәҗит Гафуриның “Сарыкны кем ашаган?” мәсәле. Габдулла Тукайның “Ике сабан” мәсәле | Таныш булган мәсәлләрне искә төшерү, эчтәлекләрен сөйләп карау. Мәсәлне уку, анализлау, идеяне чыгару. Әсәрне уку, эчтәлеген аңлау, фикер алышу, идеясен билгеләү | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 14 | Практик дәрес. Сәнгать төре буларак матур әдәбият; чәчмә һәм тезмә әсәр әсәрләрдән сурәтләү чараларын табу. Шигырь белән язылган әсәрнең сәнгать чараларын билгеләү | Хикәядәге сурәтләү чараларын табу, аларның әһәмиятен билгеләү. Шигырь тезмәләренең озынлыгын билгеләү; ритм, рифмаларны күзәтү, нәтиҗәләр ясау | 1 |
| 15 | Габдулла Тукайның “Пар ат”, “Туган җиремә”, “Туган авыл” шигырьләре | Шигырьләрне уку, анализлау, хис-сәбәп бәйләнешен ачыклау, сурәтләү чараларын табу | 1 |
| 16 | Шәүкәт Галиев. Балалар әдәбиятындагы урыны; геройлары, образлар дөньясы. “Һәркем әйтә дөресен”, ”Тереклек суы”, ”Курыкма, тимим!”, “Тарихтан сабак”, ”Өйгә бирелгән эш”, ”Онытылган, өйдә калган” шигырьләре | Шигырьләрне сәнгатьле итеп уку, төп фикерне аерып чыгару, фикер алышу | 1 |
| 17 | Д.Т.У. Фаил Шәфигуллинның “Акмөгез” хикәясе Ф.Яруллин “Сез иң гүзәл кеше икәнсез” | Әсәрне уку, анализлау, фикер алышу | 2 |
| 18 | Проект яклау. | Иҗади эш башкару, аны яклау | 1 |
| 19 | Йомгаклау дәресе | Уку елы буена үткәннәрне кабатлау, әңгәмәдә катнашу, нәтиҗә ясау | 1 |
| | Барлыгы: | | 35 |

**6 нчы сыйныф**

Укыту предметының төп эчтәлеге

| № | Төп темалар | Уку-укыту эшчәнлеге | Сәгать-ләр саны |
|---|---|---|---|
| 1. | Мифлар. Дөньяны үзләштерүнең беренче баскычы буларак мифология | Халык авыз иҗаты турында белемнәрне тирәнәйтү, системалаштыру, халык авыз иҗаты һәм матур әдәбиятның уртак һәм аермалы якларын күрсәтү | 1 |
| 2. | Практик дәрес. Тема: әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма. Ә.Еники “Бала” хикәясенә анализ. | Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма турында мәгълумат туплау | 2 |
| 3. | К.Насыйриның «Әбүгалисина» повесте БСҮ. “Әбугалисина белән Әбелхарис образларына чагыштырма характеристика “ | Текстны уку, сорауларга җавап бирү, эчтәлеген ачыклау, идеясен билгеләү, әкиятләрне төрләргә аеру, аларның үзенчәлекләрен билгеләү | 3 |
| 4. | Г.Ибраһимов. «Алмачуар» хикәясе | Әсәр буенча әңгәмә кору, үз мөнәсәбәтләрен белдереп, әкиятнең эчтәлеген сөйләү | 2 |
| 5. | Г.Рәхим. «Яз әкиятләре» хикәясе | Текстны уку, сорауларга җавап бирү, эчтәлеген ачыклау, идеясен билгеләү, әкиятләрне төрләргә аеру, аларның үзенчәлекләрен билгеләү | 1 |
| 6. | Дәрдемәнд. «Видагъ»,“Каләмгә хитаб” | Шигырьләрне уку, анализлау, хис-сәбәп бәйләнешен ачыклау, сурәтләү чараларын табу | 1 |
| 7. | С Рәмиев. «Уку»,“Авыл”шигырьләре | Шигырьләрне уку, анализлау, хис-сәбәп бәйләнешен ачыклау, сурәтләү чараларын табу | 1 |
| 8. | Г.Камал. «Беренче театр» комедиясе | “Ак бүре”, “Үги кыз” әкиятләрендәге образларны тикшерү, әңгәмәдә катнашу. “Образ (сурәт)”, “поэтика” төшенчәләрен өйрәнү | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9. | Г.Тукай “Исемдә калганнар”<br>БСҮ. Сочинение.“Бәләкәй Апуш ничек зур Тукай | Әдәби әкиятләргә мисаллар китерү. Эчтәлекләрен искә төшереп сөйләү. Әкият-уку һәм анализлау. Поэмада вакыйгаларны, төп геройларны күрсәтү | 3 |
| 10. | Практик дәрес.Тема: Лирик әсәрне анализлау.<br>Лирик жанрлар: пейзаж лирикасы; табигать образлары | Пейзаж лирикасы; табигать образлары турында мәгълумат туплау | 1 |
| 11. | Һ. Такташ. “Урман”, “Пи-би-бип”, ”Болай гади җыр гына” шигырьләре | Шигырьдәге сурәтләү чараларын табу, аларның әһәмиятен билгеләү | 1 |
| 12. | И.Газиның «Кояш артыннан киткән тургай” хикәясе. | Укытучы сөйләвен тыңлау, язучы биографиясе буенча хронологик таблица төзү. Әсәр буенча әңгәмә кору, үз мөнәсәбәтләрен белдереп, әсәрнең эчтәлеген сөйләү | 1 |
| 13. | ДТУ. И.Гази. “Өч Мәхмүт” хикәясе | Әсәрне уку, биремнәрне үтәү, геройга бәя бирү | 1 |
| 14. | Р.Батулла. «Имче», “Көчек”,”Чагыр” хикәяләре. | Хикәяләрне уку, анализлау, хис-кичерешләргә, геройларга бәя бирү, сурәтләү чараларын табу, хикәянең үзенчәлекләрен билгеләп, төшенчә итеп чыгару | 2 |
| 15. | Ф.Яруллинның “Ак төнбоек” хикәясе. | Текстны уку, сорауларга җавап бирү, эчтәлеген ачыклау, идеясен билгеләү, әкиятләрне төрләргә аеру, аларның үзенчәлекләрен билгеләү | 2 |
| 16. | ДТУ. Ф.Яруллин. “Урман әкияте” хикәясе. | Әсәрне уку, эчтәлеген аңлау, фикер алышу, идеясен билгеләү | 1 |
| 17. | Р.Миңнуллин шигырьләре | Шигырь тезмәләренең озынлыгын билгеләү; ритм, рифмаларны күзәтү, нәтиҗәләр ясау | 1 |
| 18. | М.Җәлил. «Сандугач һәм чишмә» балладасы | Шигырьләрне уку, анализлау, хис-сәбәп бәйләнешен ачыклау, сурәтләү чараларын табу | 1 |
| 19. | ДТУ.М.Җәлил. “Ана бәйрәме” шигыре | Шигырьләрне сәнгатьле итеп уку, төп фикерне аерып чыгару, фикер алышу | 1 |
| 20. | Илдар Юзеев. “Бакчачы турында баллада”, | Балладаларны уку, анализлау, фикер алышу | 1 |
| 21. | Ә.Фәйзи “Тукай” романы (өзекләр).<br>БСҮ. Сочинение “Габдулла Тукай образын гәүдәләндергән сәнгать әсәрләре”. | Тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, иҗади эш башкару. | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 22. | Проект яклау. | | 1 |
| 23 | ДТУ. Л.Шагыйрьҗан. “Тукай тавышы” поэмасы. | Шигырь тезмәләренең озынлыгын билгеләү; ритм, рифма үзенчәлекләре | 1 |
| 24 | Йомгаклау. | Дәрестән тыш әдәби әсәрләр уку, аларның эчтәлеген сөйли алу | 1 |
| | Барлыгы: | | 35 |

7 нче сыйныф

| № | Төп темалар | Уку-укыту эшчәнлеге | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1 | **Төрләр һәм жанрлар**. Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма. Әдәби алымнар (кеше образы тудыруга караган алымнар). Әдәби төр, жанр, эчтәлек һәм форма, әдәби алымнар турында белемнәр системага салына, тирәнәйтелә.<br>**Сәнгать төре буларак әдәбият.** Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормыш моделен төзү үзенчәлекләре. Тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып–белү чарасы буларак әдәбият. Аның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы. | Укылган текстның эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, төп билгеләмәләрне язып бару. | 1 |
| 2 | **Халык авыз иҗаты.** Дастан жанрына хас сыйфатлар, аның төркемчәләре. Тарихи дастан буларак «Идегәй» дастаны (өзекләр). | Укылган текстның эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, фольклор әсәрләре-нең жанрын һәм аларга хас үзенчәлекләрне таба белү, фикерләрнераслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу, яттан сөйләү | 2 |
| 3 | **XX гасыр башы**нда сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы, язучылар-ның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби–эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу. | Укылган текстның эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, план-конспект төзү. | 1 |
| 4 | **Г.Тукай тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.**«Милләтә», “Милли моңнар”, “Өзелгән өмид”, “Шагыйрь”, “Театр” шигырьләре. Гражданлык лирикасы, автор позициясе төшенчәләре. | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, шигъри текстларны яттан сөйләү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба , әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын аера белү. Фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу | 3 |
| 5 | **Н.Думавиның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү..**«Яшь | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, язу- | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | ана» хикәясе.Әсәрдә хикәя жанры үзенчәлекләренең чагылышы.Әдәби әсәрдәге образлылык. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. | чының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләү; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, план төзи белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; хикәя жанры үзенчәлекләрен әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар күрә, аера белү. | |
| 6 | **Ш.Камалның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Акчарлаклар» повесте (өзекләр). Әсәрдә жанр үзенчәлекләренең чагылышы. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Табигать образы, әйбер образы. Пейзаж, портрет. Психологизм. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт образы (хронотоп). | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу; укы-ган әсәр эчтәлеге буенча терәк схема, план төзи белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; жанр үзенчәлекләрен билгели белү; әдәби әсәрдәге образлылык, образ, символ, деталь, аллегория, табигать образы, әйбер образы, пейзаж, портрет һ.б.күрә, аера белү. | 2 |
| 7 | **Чор: 1920-1930 еллар әдәбияты. Әдәби барышка тәэсир иткән тарихи сәбәпләр. Аларның әдәбиятны каршылыклы үсешкә китерүе.** Әдәби әсәрләр төрлелек**:** милли традицияләрне дәвам иттерүче һәм яңа идеология кысаларында иҗат ителгән әсәрләр. | Укылган текстның эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, план-конспект төзү. | 1 |
| 8 | **Һ.Такташның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** “Мокамай” поэмасы. Лиро-эпик жанр - поэма. Лирик һәм эпик төр сыйфатларының поэма жанрында чагылышы. Персонаж, характер. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Әдәби әсәрдә урын һәм вакыт.Текст: эпиграф, багышлау. | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, шигъри текстларны яттан сөйләү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алынарын аера белү;. фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу, әдәби әсәрне сюжет–композиция, образлар бирелеше, тел–стиль ягыннан анализлау | 1 |
| 9 | **Г.Исхакыйның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.**«Җан Баевич» комедиясе. Драма төренең комедия жанры турында белгәннәрне тулыландыру. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). | Комедия жанрын, аңа хас үзенчәлекләрне тану, әдәби әсәр төрләрен, жанрларын таный, аера, аларга хас үзенчәлекләрне таба белү, фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу. Драма әсәрләрен аңлы һәм сәнгатьле укый белү; укыганны телдән сурәтләп бирү. | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 10 | **Г.Ибраһимовның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** “Кызыл чәчәкләр” повесте.Эпик жанрлар турындагы белемнәрне киңәйтү. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре**.** | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу; укы-ган әсәр эчтәлеге буенча терәк схема, план төзи белү; проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү; жанр үзенчәлекләрен билгели белү; әдәби әсәрдәге образ, символ, деталь, аллегория, эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. тема, проблема, идея, пафос. һ.б.күрә, аера белү. | 2 |
| 11 | **Чор әдәбияты.** ХХ гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы, аның тарихи сәбәпләре.Әдәбиятның яңалыкка омтылышы: яңа иҗади агымнарга, жанр формаларына, темаларга мөрәҗәгать итү, әдәби герой мәсьәләсендә эзләнүләр**.** | Укылган текстның эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, план-конспект төзү. | 1 |
| 12 | **С.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Әнкәй», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...» шигырьләре. Лирик жанр - күңел лирикасы. Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Тезмә сөйләм үзенчәлекләре. | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, шигъри текстларны яттан сөйләү; эзләнү эшчәнлеге: проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын аера белү;. фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу | 2 |
| 13 | **Ә.Еникинең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Әйтелмәгән васыять» хикәясе.Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь, аллегория. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче геройлар, җыелма образлар. Персонаж, характер, тип. Хикәяләүче, автор образы, автор позициясе. | Әдәби текстны укый һәм эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләү; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, план төзи белү; эзләнү эшчәнлеге: проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, әсәр композициясе үзенчәлекләрен күрә, аера белү. | 2 |
| 14 | **Ш.Хөсәеновның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Әни килде» драмасы. Драма төренең драма жанрына хас үзенчәлекләр. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әдәби иҗат. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). | Жанрны һәм аларга хас үзенчәлекләрне тану, әдәби әсәр төрләрен, жанрларын таный, аера, аларга хас үзенчәлекләрне, фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу. Драма әсәрләрен аңлы һәм сәнгатьле укый белү; укыганны телдән сурәтләп бирә алу, яттан сөйләү | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 15 | **Г. Сабитовның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Тәүге соклану», “Ярсулы яз” хикәяләре. Композиция: әсәр кору алымнары. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. | Әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле уку; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, план төзи белү. проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, композиция: әсәр кору алымнарын күрә, аера бел; тема, проблема, идея, пафос, вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст, конфликт, сюжет, сюжет элементларын дөрес билгеләү | 1 |
| 16 | **М.Мәһдиевнең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Без кырык беренче ел балалары» повесте. Хикәяләүче, автор образы, автор позициясе. Әсәрнең геройлары. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту (ретроспекция). | Әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле уку; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, план төзи белү. проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, әсәрдә кулланылган сурәтләү алымнарын, әсәр композициясе үзенчәлекләрен күрә, аера белү, яттан сөйләү | 2 |
| 17 | **М.Галиевның тормыш юлына кыскача күзәтү. “Уйна әле” хикәясе.** Эпик жанрлар турындагы белемнәрне киңәйтү. Әдәби әсәрдәге образлылык. Тема, проблема, идея. Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. | Әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле уку; укыганны телдән сурәтләп бирә алу. Проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, композиция: әсәр кору алымнарын күрә, аера белү; тема, проблема, идея, вакыйга, күренеш, сюжет, сюжет элементларын дөрес билгеләү | 1 |
| 18 | **Г.Гыйльмановның тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Язмышның туган көне» хикәясе. Эчтәлек: вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст. Конфликт, сюжет, сюжет элементлары. | Әдәби әсәрләрне аңлы һәм сәнгатьле уку; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, план төзи белү. проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, вакыйга, күренеш, яшерен эчтәлек, контекст, конфликт, сюжет, сюжет элементларын күрә, аера белү | 2 |
| 19 | **З.Хәкимнең тормыш юлы һәм иҗатына кыскача күзәтү.** «Сәер кыз» драмасы. Драма төренең драма жанрына хас үзенчәлекләре. Тема, проблема, идея. Идеал. Сәнгати алымнар һәм стиль. | Драма жанрын һәм аңа хас үзенчәлекләрне тану, әдәби әсәр төрләрен, жанрларын таный, аера, аларга хас үзенчәлекләрне, сәнгати алымнарны таба белү, фикерләрне раслар өчен әсәрдән дәлилләр таба алу. Драма әсәрләрен аңлы һәм сәнгатьле укый белү; укыганны телдән сурәтләп бирә алу | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 20 | **Р.Харисның тормыш юлына кыскача күзәтү. «Сабантуй» поэмасы.** Лиро-эпик жанр - поэма. Лирик һәм эпик төр сыйфатларының поэма жанрында чагылышы. Персонаж, характер. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Милли бәйрәмнәр, гореф-гадәтләр. | Әдәби әсәрне аңлы һәм сәнгатьле уку; укыганны телдән сурәтләп бирә алу; укыган әсәр эчтәлеге катламнарына бәйле терәк схема, план төзи белү, проблемалы сорауларга мөстәкыйль рәвештә җавап таба белү, Композиция: тышкы һәм эчке корылыш элементларын күрә, аера белү. Милли бәйрәм, гореф-гадәтләр турында фикер алышу | 1 |
| 21 | **Р. Фәйзуллинның тормыш юлына кыскача күзәтү.** "Биеклек", "Туган тел турында бер шигырь" әсәрләре, лирик жанрларны тану күнекмәсен үстерү, лирик герой сыйфатларын билгеләү. | Әдәби текстны укый, эчтәлеген кабатлап сөйли, аңлата алу, шигъри текст яисә чәчмә әсәрдән өзекне яттан сөйләү; сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлы, иҗаты турында сөйләү | 1 |

8 нче сыйныф

| № | **Бүлекләр исемлеге** | **Бүлек, эчтәлек** | **Сәгатьләр саны** |
|---|---|---|---|
| **1** | Сәнгать төре буларак әдәбият. | Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормыш моделен төзү үзенчәлекләре. Тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып–белү чарасы буларак әдәбият. Аның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы. | 1 |
| **2** | **Урта гасырлар әдәбиятында дини-суфичыл әсәрләр.** | Урта гасырлар әдәбияты. Казан ханлыгы чоры. Казан ханлыгы чорына кыскача тарихи, мәдәни, әдәби күзәтү.<br><br>Мөхәммәдьярның тормыш юлы турында мәгълүмат. «Нәсыйхәт» шигыре. | 2 |
| **3** | **XIX гасыр әдәбияты. Мәгърифәтчелек әдәбияты**.<br><br>. | XIX гасыр әдәбияты. Чорга кыскача тарихи күзәтү. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте. Муса Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» повесте. | 2 |
| | | **Сөйләм үстерү**. Төп образларга характеристика язу | 1 |
| **4** | **XX гасыр башы татар әдәбиятының үзенчәлеге.**<br><br>Чорга кыскача тарихи күзәтү. XX гасыр башында сүз сәнгатенең | XX гасыр башы әдәбияты. Чорга кыскача тарихи күзәтү. М.Гафуриның «Нәсыйхәт» шигыре. | 1 |
| | | Габдулла Тукайның «Тәэссер», «Ана догасы», «Таян аллага», “Нәсыйхәт” шигырьләре.. | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы, язучыларның әхлакый, фәлсәфи һәм әдәби–эстетик эзләнүләре, тәҗрибәләр. Яңа тип геройлар мәйданга чыгу.<br><br>**XX гасыр башы татар әдәбиятында дини-суфичыл әсәрләр.** | **Бәйләнешле сөйләм үстерү** Сочинение. Г.Тукай иҗатында дин фәлсәфәсе. | 1 |
| **5** | **XX гасыр башы татар әдәбиятында психологизм** | Шәриф Камалның «Буранда» хикәясе.<br><br>Язучының тормыш юлын искә төшерү. «Буранда» хикәясендә авторның төп максаты – Мостафаның кичерешләрен аңлату. Ананың хәсрәтле тормышы, төп геройның үкенү сәбәпләре икесенә карата да кызгану хисләре уята. Буран образы – адаштыра торган табигать күренеше генә түгел, Мостафаның әнисенә булган мөнәсәбәтендә зур ялгышуы, адашуы, хәзерге хисләре, күңел халәте. Әсәрнең фаҗигале тәмамлануы, аеруча үкенеч белән тасвирлануы хикәяне онытылмаслык итеп истә калдыра. Әдәби төр, жанрын билгеләү. Образлар системасы: 6кеше, табигать яки әйбер, ясалма образлар. Кеше образлары: төп геройлар, ярдәмче геройлар, катнашучы геройлар, аталучы геройлар һәм җыелма образлар. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту. Троплар. Әсәрнең пафосы – сентименталь пафос. Язучы стиле. Әдәбиятта нәфис-бизәкле стиль. Трансцендентальлек. Көчле позиция. | 1 |
| **6** | **XX гасыр башы татар әдәбиятында сызлану фәлсәфәсе.** | Фатих Әмирханның «Бер хәрабәдә» хикәясе.<br><br>Язучының тормыш юлын искә төшерү. Хикәядә авыр, кайгылы хәлләрнең сурәтләнүе. Матурлык, Яшьлек, Мәхәббәт, Бәхетнең вакытлы булуы аша тормышның мәгънәсе юклыкка төшенү. Әсәрнең эчке катламын музыка аша бирү: Сөләйман карт елавы, капка, кыңгырау, бакча, сандугач тавышы, гитараның моңлы | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | уйнавы, карчыкның йөткерүе карга каңгылдавы. Әдәби төр, жанрын билгеләү. Образлар системасы: кеше, табигать яки әйбер, ясалма образлар. Кеше образлары: төп геройлар, ярдәмче геройлар, катнашучы геройлар, аталучы геройлар һәм җыелма образлар. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую, үткәнгә әйләнеп кайту.Троплар. Әсәрнең пафосы (сентименталь пафос), фәлсәфи фикерләр белән баетылуы. Язучы стиле: хикәя тормыш –яшәешкә ләгънәт укый, экзистенциализм фәлсәфәсен белдерә. | |
| | | **БСҮ**.Фатих Әмирханның «Бер хәрабәдә» хикәясенә бәя | 1 |
| | | Кәрим Тинчурин “Искәндәр” хикәясе | 1 |
| **7** | **XX гасыр татар әдәбиятында мәхәббәт фәлсәфәсе.** | Фәтхи Бурнашның «Таһир-Зөһрә» трагедиясе.<br><br>Язучының тормыш юлы белән танышу. «Таһир-Зөһрә» трагедиясен уку. Драма төренә анализ ясау үзенчәлекләрен искә төшерү. Конфликтын билгеләү. Шигырь белән язылган, дастан сюжетына нигезләнгән булуы, дөнья әдәбиятында киң таралган мәхәббәт һәм мәкер, гаделлек һәм явызлык көрәше. Трагедиянең пафосын (трагик пафос), язучы стилен билгеләү – әдәбиятта нәфис-бизәкле стиль. | 2 |
| **8** | **20 – 30 нчы еллар әдәбиятында мәхәббәт фәлсәфәсе һәм яңа тормыш өчен көрәш романтикасы.**<br><br>30 нчы еллар әдәбиятында көрәш романтикасын сурәтләү. Тормышны матурлап, шартлылык кануннарына буйсындырып тасвирлау. Заманга хас яңа герой эзләү. Әдәби барыш: чор әдәбияты. | 20 – 30 нчы еллар әдәбияты. Әдәби барыш: чор әдәбияты.<br>Һади Такташның «Алсу» поэмасы.<br><br>Үз чорының кичерешләрен, каршылыкларын чагылдырган иң популяр, танылган шагыйрь, прозаик, драматург буларак тормышы, иҗаты белән таныштыру. «Алсу» поэмасында яшьлекнең, көрәш романтикасының сурәтләнеше. Әдәби төр һәм жанрлар. Лиро-эпик жанр – поэма. Әдәби әсәрдәге образлылык. Образ, символ, деталь. Кеше образлары: төп герой, ярдәмче герой, катнашучы геройлар, җыелма образлар. Характер. Лирик герой, лирик “мин”, автор образы, автор позициясе. Әдәби әсәр. Эчтәлек һәм форма. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья. Пейзаж, портрет. Әдәби иҗат. Сәнгати алымнар һәм стиль. Әдәби алымнар: кабатлау, янәшәлек, каршы кую. Тел–стиль чаралары (лексик, | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Тезмә һәм чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. Ритм һәм рифма, тезмә, строфа. | |
| | | Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте.<br>Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Конфликт, сюжет, сюжет элементлары. Композиция: тышкы һәм эчке корылыш. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Психологизм.<br>Мәхәббәт, гаилә кору темасын ачу. Конфликтның кемнәр арасында баруы, сәбәпләре, чишелеше ягыннан әсәрне анализлау. Төп конфликтның эчке конфликт булуына басым ясау. Галиянең хатларны үзе өчен язуын ачыклау. Сюжет этапларын ачу. Эпистоляр повесть жанры.<br>БСҮ.Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повесте буенча сочинение | 2 |
| | | Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасы.<br>Әдипнең тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Драма әсәрләренә анализ ясау үзенчәлекләре. Фаҗигале драма жанрында язылган әсәрнең сюжет-композициясен ачыклау. Кеше бәхете темасының бирелеше, драманың проблема, идеясен билгеләү . Төп образларга характеристика бирү, сәнгатьчә эшләнешен өйрәнү. Портрет. Психологизм . Язучы стиле - фаҗигале). | 2 |
| | | **БСҮ**. Сочинение. “Кәрим Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасында күтәрелгән проблемалар” яки “Һәркемнең бәхетле булырга хакы бар.” | 1 |
| **9** | **Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты.** | Фатих Кәримнең «Сибәли дә сибәли», «Ант», «Ватаным өчен», «Теләк», «Сөйләр сүзләр бик күп алар», «Бездә яздыр», «Газиз әнкәй» шигырьләре. «Кыңгыраулы яшел гармун» поэмасы | 1 |
| **10** | **60-80 нче еллар әдәбияты.**<br>. | Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» автобиографик повесте.<br>Тормыш юлы турында мәгълүмат.. Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» автобиографик повесте. (кыскартып). Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Повестьта халык тормышының тулы бер панорамасы чагылу. Әсәрдә туган ил, | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | халкың белән горурлану хисе тасвирлана, повесть укучыларда хезмәткә, туган җиргә мәхәббәт тәрбияли. Сурәтләнгән геройларның, вакыйга-күренешләрнең тормышчан булуы, шулар аша әдип татар авылының үткәнен һәм бүгенгесен, борынгыдан килгән гореф-гадәтләрен, йолаларын, халыкның күңел байлыгын, гомумән, милли сыйфатларын тасвирлый. Г.Бәширов - портрет, табигать бизәкләре, характер остасы; Гумәр образының бирелеше. Тел–стиль чаралары (лексик, стилистик, фонетик чаралар һәм троплар). Әдәби сөйләм: хикәяләү, сөйләшү (диалог), сөйләү (монолог). Чәчмә сөйләм үзенчәлекләре. Язучы стиле. | |
| | | Аяз Гыйләҗевнең “Язгы кәрваннар” повесте. Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Повестьта халык тормышының тулы бер панорамасы чагылу. Әсәрдә туган ил, халкың белән горурлану хисе тасвирлана, повесть укучыларда хезмәткә, туган җиргә мәхәббәт тәрбияли. Сурәтләнгән геройларның, вакыйга-күренешләрнең тормышчан булуы, шулар аша әдип татар авылының үткәнен һәм бүгенгесен, борынгыдан килгән гореф-гадәтләрен, йолаларын, халыкның күңел байлыгын, гомумән, милли сыйфатларын тасвирлый | 2 |
| | | Миргазиян Юныс “Биектә калу” (“Шәмдәлләрдә генә утлар яна”) повесте. Язучының тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Повесть жанры. Хикәяләү, сурәтләү, бәяләү катламнары. Әдәби әсәрдәге образлылык: әдәби деталь, җыелма һәм символик образларның әсәр эчтәлеген ачудагы әһәмияте. Повестьны эчтәлек һәм форма ягыннан анализлаганда, хронотоп, архетипны ачыклау. Тел-стиль чаралары. Әсәр исеменең эчке һәм тышкы мәгънәгә ия булуы. Заманга тәнкыйди бәя. Язучы стиленең үзенчәлекләре | 2 |
| | | Равил Фәйзуллинның «Җаныңныңваклыгын сылтама заманга…», «Аккошлар», «Мин сиңа йомшак таң җиле…»“Вакыт”, “Якты моң”, һәм кыска шигырьләре.<br><br>Шагыйрьнең тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Иҗатка 60 нчы елларда килүе, яңача ритмика, рифма, образлар системасы тудыруы. Р.Фәйзуллин кыска формаларга мөрәҗәгать итә, аларда метафора алгы планга чыга. Лирик әсәрләргә | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | анализ ясау үзенчәлекләре. Табигый хис-кичерешләр чагылыш тапкан шигырьләренең җырлар булып китүе. Фәлсәфи лирика<br>Мөдәррис Әгъләмовның «Каеннар булсаң иде», «Учак урыннары» шигырьләре. | |
| | | Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» моңсу комедиясе. Әдипнең тормыш юлы турында мәгълүмат бирү. Драма әсәрләренә анализ ясау үзенчәлекләре. Каршылыкның төрләре: төп сюжет сызыгында тышкы каршылык Әлмәндәр һәм Әҗәл арасында, эчке каршылык Әҗәл күңелендә; ярдәмче сюжет сызыкларында тышкы каршылык Әлмәндәр белән Өммия, Әлмәндәр белән Искәндәр арасында формалаша. Төп сюжет сызыгындагы эчке каршылыкның төп каршылык булуы. Әсәрнең фәлсәфи фикерләр белән баетылуы. Әлмәндәр образының бирелеше, аның замандаш сыйфатларын туплаган, халыкчан образ-характер булуы. Комедиянең тел-сурәтләү чараларына, кинаяле тезмәләргә байлыгы. Реаль тормыш картиналарының шартлылык һәм символлар белән тыгыз кушылып китүе, шуның белән әсәрдәге төп идеяне тулырак ачуга ирешү. | 2 |
| | | Фәнис Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повесте.<br>Әдипнең тормышы, иҗаты турында мәгълүмат бирү. «Җилкәннәр җилдә сынала» повестеның – автобиографик повесть булуы. Кешене данлау, зурлау темасының бирелеше. Тема, проблема, идея, пафос. Идеал. Язучы стиле. | 2 |
| | | ДТУ. Мәдинә Мәликова “Чәчкә балы” яки Фәүзия Бәйрәмова “Кыңгырау” | 1 |
| | ДТУ. Татар әдәбиятында шагыйрәләр иҗаты: Л.Шагыйрьҗан, Э.Мөэминова, Н.Сафина, Р.Вәлиева, Б.Рәхимова, Э.Шәрифуллина, А.Минһаҗева. Шагыйрәләр иҗатын өйрәнеп, проектлар яклау дәресе.<br>Хәзерге татар әдәбиятында яшьләр иҗаты. **Проектлар яклау** | | 1 |
| | Барлыгы | | 35 |

9 нчы сыйныф

| № | Бүлекләр исемлеге | Бүлек, эчтәлек | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|---|
| 1. | **Сәнгать төре буларак әдәбият** | Сәнгать төре буларак әдәбият. Сәнгатьнең табигате. Әдәбиятның башка сәнгать төрләре арасында урыны. Сүз сәнгатендә тормышның әдәби чагылышы. Әдәбиятның тормышны һәм кешенең бай рухи дөньясын танып белүгә хезмәт итүе. Әдәбиятның әхлакый һәм эстетик яктан кешегә йогынтысы | 1 |
| 2. | **Борынгы, урта гасырлар гомумтөрки әдәбият** | Борынгы, урта гасырлар гомумтөрки әдәбият. Төрки халыклар, татарларның борынгы бабалары турында тарихи-әдәби мәгълуматлар. Борынгы, урта гасырлар төрки-татар әдәбиятының үсеш этаплары. Татар әдәбиятының бер өлеше буларак гомумтөрки әдәбияты һәм фольклоры.Орхон-Енисей истәлекләре. Аларда борынгы төрки халыкларының тарихы, ышануы, әдәби фикерләү үзенчәлекләренең чагылышы. Борынгы төрки фольклорын һәм язма әдәбиятын өйрәнү чыганагы буларак М.Кашгариның “Диване лөгат эт-төрк” әсәре. Й.Баласагунлы “Котадгу белек”–төрки халыкларының беренче классик поэмасы.XII-XIII гасырларда Болгар-татар әдәбияты. К.Гали “Кыйссаи Йосыф”- кеше хисләренең бөеклеге, матурлык, зирәклек гимны.Татар әдәбиятында Яңарыш чоры буларак Алтын Урда әдәбияты . Котб, Сәиф Сараи, Хәрәзми иҗаты. Төрки-татар әдәбиятында суфичылык юнәлеше.Казан ханлыгы чоры әдәбиятына гомуми бәяләмә.Казан ханлыгының рус дәүләтенә кушылуы. М.Колыйның фәлсәфи-дидактик хикмәтләрендә татар җәмгыятенең кризис хәленең чагылуы. | 6 + 1 сәг.БС |
| 3 | **XIX гасыр татар әдәбияты** | XIX гасыр татар әдәбияты. Г.Курсави, И.Хәлфин, К Насыйри, Ш.Мәрҗәни, Х.Фәизханов, И.Гаспринскийның мәгърифәтчелек эшчәнлеге.Г.Кандалый, Акмулла иҗатында реалистик поэзия формалашу. Татар реалистик прозасы формалашу. | 1 |
| 4 | **З.Бигиев** | Әдәбиятта яңа төрләр һәм жанрлар барлыкка килү.З.Бигиевнең«Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романы... Татар халкының үсеш яңарыш кичерүе өчен, мондый темаларның актуаль булуы, татар хатын-кызы язмышы, рус мәдәниятенә йөз тоту. | 2 |
| 5 | **20 гасыр башы татар** | 20 гасыр башы татар әдәбияты. Сүз сәнгатенең шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни | 2 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **әдәбияты** | казанышларын үзләштерүе. Ф.Әмирханның. «Хәят» повесте. Модернизм, модернизм алымнары. | |
| 6 | **Г.Камал “Банкрот”** | Г.Камал “Банкрот” | 2 |
| 7 | **XX гасырның беренче яртысында татар әдәбияты** | XX гасырның беренче яртысында татар әдәбияты. 1917 елдан соңгы татар әдәбияты үсешендәге кыенлыклар. Эпик төрнең бер жанры буларак романның активлашуы. М.Галәү “Мөһаҗирләр” романы. | 2+ 1 сәг. БСҮ |
| 8 | **Бөек Ватан сугышы, аның әдәбиятка йогынтысы** | Бөек Ватан сугышы, аның әдәбиятка йогынтысы. Сугыә еллары поэзиясенең төп тема-мотивлары, образлары, поэтикасы. Г.Кутуйның «Сагыну» нәсере. Муса Җәлилнең «Тик булса иде ирек» шигыре, “Җырларым”. Ә.Еникинең “Кем җырлады” хикәясе. М.Җәлилнең тормыш юлы һәм иҗаты. | 3 + 1 сәг. Проект яклау |
| 9 | **1940-50 нче еллар поэзиясендә фәлсәфи-лирик юнәлеш** | Х.Туфан иҗатының чорларга бүленеше. «Кайсыгызның кулы җылы» шигыре. Х.Туфанның «Киек казлар» шигыре. 1940-50 нче еллар поэзиясендә фәлсәфи-лирик юнәлеш. Поэтика һәм стиль үзенчәлекләре. | 2 |
| 10 | **XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты** | XX гасырның икенче яртысында татар әдәбияты. XX гасырның икенче яртысында татар әдәбиятының милли нигезләргә кайтуы. А.Гыйләҗевның «Җомга көн, кич белән» повесте. Татар әдәбиятының милли традицияләргә кайтуы. | 1+1 БСҮ |
| 11 | **Тарихи роман.**<br>**Н. Фәттах** | Тарихи роман. Н. Фәттахның . “Ител суы ака торур» романы | 2 |
| 12 | **XX-XXI гасырлар чигендә татар әдәбияты** | XX-XXI гасырлар чигендә татар әдәбияты. XX-XXI гасырлар чигендә татар әдәбиятының үзгәрүе: совет һәм аннан соңгы чорга тәнкыйди бәя.Зөлфәтнең «Тамыр көлләре»шигыре. Зөлфәтнең«Тойгыларда алтын яфрак шавы» шигыре | 1 |
| 13 | **Совет чоры җәмгыятенең актуаль проблемалары** | Совет чоры җәмгыятенең актуаль проблемалары. Кеше һәм җәмгыять каршылыгы күзлегеннән ил тормышының аерым этапларын сурәтләүче әдәби әсәрләрнең барлыкка килүе. Ф.Садриевның «Таң җиле» романы. | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 14 | **Т.Миңнуллин “Кулъяулык” әсәре** | Халык традицияләрен саклау һәм яңарыш проблемалары. Т.Миңнуллин “Кулъяулык” әсәре. | 2 |
| 15 | **Кабатлау** | 9 нчы сыйныфта үтелгәннәрне кабатлау һәм гомумиләштерү | 1 |
| **Барлыгы** | | | **35** |

В данной рабочей программе по
_родной (татарской) литературе_
для _5-9_ классов прошнуровано,
пронумеровано, скреплено печатью
_70 (семьдесят)_ страниц
Директор МБОУ «Каракашлинская
ООШ» ________ Э.Ф.Ахметова